**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«30» октября 2020 ел № 398

«2021 елга «Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмаларының махсус билгеләнгән автобуслар белән укучыларны ташу эшен оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең норматив чыгымнарын раслау турында»

1. 2021 елга расларга:

2021 елга гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын;

гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмәне.

2. «Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасы әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә укучыларны махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүне финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, финанс-бюджет палатасы рәисе Ф. И. Гыймадиевка йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Каюмов

Расланды
Әтнә районы башкарма комитеты карары белән
«30» 10 2020 № 398

2021 елга «Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмаларының махсус билгеләнгән автобуслар белән укучыларны ташу эшен оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең норматив чыгымнары

| Автотранспорт чарасы моделе | Норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, еллык сум | автотранспорт чарасы узышының бер километрына ставка, сум |
| КАВЗ | 149595 | 37,79 |
| ПАЗ | 149072 | 37,72 |
| ГАЗ «Газель» | 129791 | 30,61 |
| УАЗ | 129338 | 29,21 |
| FIAT | 132984 | 27,71 |
| Peugeot Boxer | 138182 | 27,36 |
| Ford Transit | 138440 | 30,79 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 151544 | 35,91 |

Расланды
Әтнә районы башкарма комитеты карары белән
«30» 10 2020 № 398

Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү механизмын билгели (алга таба - муниципаль хезмәт).

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм хисап чорында автотранспорт чараларының фактагы йөгереше нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен «Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының фактагы йөгереше турында мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча автотранспорт чарасы маршрутының расланган паспорты кысаларында башкарылган автотранспорт чарасының фактагы йөреше буларак кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. муниципаль берәмлек муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

где:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - m модельле автотранспорт чараларының фактта йөреше, километр;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру нормативы ставкасы бер километрга, сумнарда;

$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын бер автотранспорт чарасына балаларны махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру нормативы ставкасы, сумнарда;

$M_m$ - m модельле автотранспорт чараларының саны, данә;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе атамасы;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобуслар модельләре саны.